Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXIX –7**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 2 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” XXXI-2 номерлы карарына Балык Бистәсе прокуратурасының 2018 елның 1 февралендәге 02-08-02/2018 номерлы протестын карау турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 2 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” XXXI-2 номерлы карарына Балык Бистәсе прокуратурасының 2018 елның 1 февралендәге 02-08-02/2018 номерлы протестын карап, “Россия Федерациясе прокуратурасы турында»” 1992 елның 17 февралендәге 2202-1 номерлы Федераль законның 23 маддәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Регламентының 80 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 2 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” XXXI-2 номерлы карарына Балык Бистәсе прокуратурасының 2018 елның 1 февралендәге 02-08-02/2018 номерлы протесты белән ризалашырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 2 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” XXXI-2 номерлы карарын законарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык, законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссияләренә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратының юридик бүлеге белән берлектә күрсәтелгән протесттагы таләпләрне исәпкә алучы карар проектын эшләргә һәм

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының якындагы утырышында карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның күчермәсен Балык Бистәсе районы прокурорына җибәрергә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советы рәисе урынбасары И.Г.Ибраһимов